**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.12.2025 № 1464

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат шәһәре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 29 маендагы 568 карарына үзгәрешләр кертергә

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 29 маендагы 568 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 15 гыйнварындагы 30 номерлы, 2025 елның 17 ноябрендәге 1318 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Нурлат шәһәре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибендә:

2 өлешнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану инициаторлары булып органнар сыйфатында эш итүче, бюджет керемнәре администраторлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы һәм административ керемнәр буенча беренчел документларның бюджет исәбендә тулы һәм үз вакытында чагылышын тәэмин итүче (алга таба-Башкарма комитетның тармак органы) «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин